Республика Татарстан
Совет Иляксазского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Илексаз авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ | КАРАР

14 июнь 2017 ел | №9

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советы № 10, 17.05.2014 ел карары белән расланган "Илексаз авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Сарман муниципаль районы "Илексаз авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында "Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2017 елның 1 маендагы 90-ФЗ номерлы Федераль законга яраклаштыру максатларында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Илексаз авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы «Илексаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 17.05.2014 ел, № 10 Илексаз авыл җирлеге Советы карары белән расланган Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
   1) 5.4.п. 5 бүлекләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «Ел саен түләүле төп ял муниципаль хезмәткәргә 30 календарь көн дәвамында бирелә".
   2) 5.5 п. 5 бүлекләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
   «Ел саен өстәмә түләүле отпусклар муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен (10 календарь көннән дә артык түгел), шулай ук федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъекты законнарында каралган очракларда бирелә. Хезмәт көне нормалаштырылмаган муниципаль хезмәткәргә өч календарь көн дәвамында хезмәт көне нормалаштырылмаган өчен ел саен өстәмә түләүле отпуск бирелә".
2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Илексаз авыл җирлеге
Советы рәисе

Ф.М.Гильфанов

Совет Иляксазского сельского поселения
Илексаз авыл җирлеге Советы